**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ҖӨРИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**дүртенче чакырылышның кырык алтынчы утырышы**

**1 ноябрь 2024 ел** **№144** **Иске Җөри авылы**

Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге Советының 2023 елның 15 ноябре №113 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2024 елның 12 июлендәге 05-11/4815 номерлы хатын карап, Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге Советының 2023 елның 15 ноябрендәге 113 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 пунктның 2 пунктчасында “, шулай ук һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата” сүзләрен төшереп калдырырга;

– түбәндәге эчтәлекле 2.1 пунктча белән тулыландырырга

"2.1) салым салу объектларына карата 2,5 процент, аларның һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә;";

- 2 пунктны түбәндәге редакциядәге 4 пунктча белән тулыландырырга:

«4) 2025-2027 еллар чорына 1000 квадрат метрдан артык гомуми мәйдандагы сәүдә һәм административ-эшлекле үзәкләргә (комплексларга) карата һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән биналарга карата 1,2 процент.»;

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Иске Җөри авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Мараков